| | |
|---|---|
| СОВЕТ<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО<br>ОБРАЗОВАНИЯ<br>«УРМЫШЛИНСКОЕ СЕЛЬСКОЕ<br>ПОСЕЛЕНИЕ»<br>ЛЕНИНОГОРСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЛЕНИНОГОРСК<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>«УРМЫШЛЫ<br>АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ»<br>МУНИЦИПАЛЬ<br>БЕРӘМЛЕГЕ СОВЕТЫ |

РЕШЕНИЕ КАРАР

2018 елның 29 гыйнвары № 1

Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы «Урмышлы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советының 2016 елның 3 октябрендәге 34 номерлы «Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы «Урмышлы авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт турындагы нигезләмәне раслау хакында» карары белән расланган Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы «Урмышлы авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

«Коррупциягә каршы тору турында Россия Федерациясе законнары үтәлешен тикшереп торуны камилләштерү максатларында Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2018 елның 3 августындагы 307-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы «Урмышлы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигнезендә, «Урмышлы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советы КАРАР БИРДЕ:

1. Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы «Урмышлы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советының 2016 елның 3 октябрендәге 34 номерлы «Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы «Урмышлы авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт турындагы нигезләмәне раслау хакында» карары белән расланган Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы «Урмышлыавыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешне кертергә:

19 статьяның 19.4.3 пунктына түбәндәге эчтәлекле 2.1 пунктча белән тулыландырырга:

" 2_1) коррупцион һәм башка хокук бозуларны профилактикалау буенча тиешле муниципаль органның кадрлар хезмәте бүлекчәсе доклады (анда аны кылуның факттагы шартлары бәян ителә) һәм муниципаль хезмәткәрнең язма аңлатмасы бары тик аның ризалыгы белән һәм коррупциячел хокук бозу фактын тану шарты белән генә һәм алар тарафыннан коррупциячел хокук бозу фактын тану шарты белән генә бирелә (ышаныч югалтуга бәйле рәвештә эштән азат итү рәвешендәге түләтүне кулланудан тыш);".

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы, Лениногорск районы, Урмышлы авыл җирлеге буенча урнашкан махсус җиһазландырылган мәгълүмат стендларында игълан итәргә, Лениногорск муниципаль районы рәсми сайтында (http://leninogorsk.tatarstan.ru) «Авыл җирлекләре» бүлегендә, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru/) урнаштырырга.

3.Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплыгымда калдырам.

Татарстан Республикасы
Лениногорск муниципаль районы
«Урмышлы авыл җирлеге» муниципаль
берәмлеге башлыгы вазифаларын башкаручы А.Ф.Хәбибуллин